**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 13 апрель № 223

г. Казань

Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем төзү турында

Хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларын һәм җир кишәрлекләрен билгеләү, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре әлеге объектларга хокукларны дәүләт теркәвенә алу һәм салым салу базасын киңәйтү чараларын үткәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Теркәлгән Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\223.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 13 апрель, 223 нче
карары белән расланды

**Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем турында**
**нигезләмә**

1. Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) салым салу базасыннан төшеп кала торган җир кишәрлекләрен һәм күчемсез милек объектларын билгеләүнең нәтиҗәле механизмын эшләү өчен оештырылды.

2. Эшче төркем Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән оештырыла һәм таратыла.

3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Эшче төркемнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларын һәм җир кишәрлекләрен билгеләү методикасын эшләү;

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларын һәм җир кишәрлекләрен салым әйләнешенә җәлеп итү чараларын үткәрүне оештыру;

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларын һәм җир кишәрлекләрен салым әйләнешенә җәлеп итү чаралары мониторингын һәм аларның нәтиҗәлелеге анализын үткәрү.

5. Эшче төркем үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан законнарда билгеләнгән тәртиптә үз компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

6. Эшче төркемгә йөкләнгән бурычларны үтәүне оештыруны эшче төркемнең ике рәистәше гамәлгә ашыра, алар бер үк төрле хокукларга ия була.

7. Эшче төркем утырышы кирәк булганда үткәрелә.

8. Эшче төркем карарлары утырышта катнашкан эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга утырышта катнашкан эшче төркем рәистәше имза куя.

9. Эшче төркем эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итүне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы гамәлгә ашыра.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 13 апрель, 223 нче
карары белән расланды

**Салым салу базасын киңәйтү максатларында хокуклары теркәлмәгән күчемсез милек объектларына һәм җир кишәрлекләренә инвентаризация үткәрү буенча ведомствоара эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| Нуретдинов Айрат Рәфкать улы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе, эшче төркем рәистәше (килешү буенча) |
| Хамаев Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры, эшче төркем рәистәше |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Волков Данил Вертолиевич | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Гайнетдинов Ренат Вагиз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Гимаев Илшат Сәхап улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Козачек Ирина Владимировна | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Костин Артем Петрович | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мерзакреев Рөстәм Рауф улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары |
| Мостафин Айрат Рафинант улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Самойлов Антон Витальевич | «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Тимиряев Виктор Сергеевич | Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (килешү буенча) |
| Хәмзина Лена Илдар кызы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәсбиев Раил Равил улы | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе (килешү буенча). |

F:\KARAR\2017\223-2.doc